| МИНИСТЕРСТВО СТРОИТЕЛЬСТВА, АРХИТЕКТУРЫ И ЖИЛИЩНО-КОММУНАЛЬНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТӨЗЕЛЕШ, АРХИТЕКТУРА ҺӘМ ТОРАК-КОММУНАЛЬ ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ |
| --- | --- |

№ 17/0

ПРИКАЗ — БОЕРЫК

«01» 02 2017

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) карата конкурс үткәрү хакында нигезләмә раслау турында

«Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге № 79-ФЗ Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә карата конкурс турында» 2005 елның 1 февралендәге № 112 Указы, «Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы № 3-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы нигезендә боерык бирәм:

1. Кушымта булып килүче Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) карата конкурс үткәрү хакындагы нигезләмәне расларга.

2. Юридик бүлек башлыгы Э.Ю. Латыйповага дәүләт теркәвенә алу өчен шушы боерыкның Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрелүен тәэмин итәргә.

3. Массакүләм мәгълүмат чаралары белән хезмәттәшлек секторы җитәкчесе Г.С. Миңнехановага әлеге боерыкның Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының "Интернет" мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырылуын тәэмин итәргә.

4. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының түбәндәге боерыкларын көчен югалткан дип

Документ создан в электронной форме. № 01-09-3773 от 03.03.2017. Исполнитель: Петрова С.А.
Страница 20 из 38. Страница создана: 02.03.2017 17:43
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

таныргa:

«Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында дәүләт гражданлык хезмәте вакант вазыйфаларын биләүгә карата конкурслар үткәрү хакында» 2012 елның 27 февралендәге № 41/о;

«Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында дәүләт гражданлык хезмәтенең вакант вазыйфаларын биләүгә карата конкурслар үткәрү хакында» 2012 елның 27 февралендәге № 41/о боерыгы белән расланган «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында дәүләт гражданлык хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә карата конкурс үткәрү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2013 елның 27 декабрендәге № 136/о;

«Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында дәүләт гражданлык хезмәте вакант вазыйфаларын биләүгә карата конкурслар үткәрү хакында» 2012 елның 27 февралендәге № 41/о боерыгы белән расланган «Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында дәүләт гражданлык хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә карата конкурс үткәрү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 26 маендагы № 51/о.

5. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр И.Ә.Фәйзуллин

ОТДЕЛ ОРГАНИЗАЦИОННО-ПРОТОКОЛЬНОЙ РАБОТЫ, КОНТРОЛЯ И ДЕЛОПРОИЗВОДСТВА


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

ТатарстанРеспубликасы
Төзелеш, архитектура һәм
торак-коммуналь хуҗалыгы
министрлыгының
2017 елның «01» 02
№17/боерыгы белән
расланды

# Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) карата конкурс үткәрү турында нигезләмә

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Татарстан Республикасы Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) карата конкурс (алга таба – Конкурс) үткәрүнең тәртибен, шартларын һәм методикасын билгели.

Конкурс Россия Федерациясе гражданнарының Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенә (алга таба – гражданлык хезмәте) карата тигез мөмкинлеккә ия булуының конституциячел хокукын, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренең (алга таба – гражданлык хезмәткәрләре) конкурс нигезендә вазыйфада үсү хокукын тәэмин итә.

1.2. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында (алга таба – Министрлык) конкурс «Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге № 79-ФЗ Федераль законның 22 статьясы, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә карата конкурс турында» 2005 елның 1 февралендәге № 112 Указы, «Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы № 3-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенә кадрлар резервы турында нигезләмә раслау турында» 2011 елның 14 мартындагы № ПУ-127 Указы нигезендә үткәрелә.

Конкурс Министрлыкта гражданлык хезмәте вакант вазыйфасын (гражданлык хезмәтенең кадрлар резервы вазыйфаларын) биләүгә дәгъва кылучыларның һөнәри дәрәҗәсен, аларның әлеге вазыйфага карата билгеләнгән квалификация таләпләренә туры килүен бәяләүдән гыйбарәт.

1.3. Конкурс түбәндәге максатларда үткәрелә:

сәләтләре һәм һөнәри әзерлеге нигезендә гражданлык хезмәтенә тигез үтеп керүдә гражданнарның конституциячел хокукларын, шулай ук гражданлык хезмәткәрләренең конкурс нигезендә вазыйфада үсү хокукларын

Документ создан в электронной форме. № 01-09-3773 от 03.03.2017. Исполнитель: Петрова С.А.
Страница 22 из 38. Страница создана: 02.03.2017 17:43
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

тәэмин итү;

гражданлык хезмәте вакант вазыйфасын биләү буенча аеруча туры килә торган кандидатларны законнарда билгеләнгән таләпләргә җавап бирә торган һәм конкурста катнашуга кертелгән кандидатлар саны арасыннан сайлап алу;

Министрлыкның кадрлар резервын формалаштыру.

1.4. Конкурс үткәргәндә хәл ителә торган мәсьәләләр:

барлык кандидатларга конкурс биремнәрен һәм процедураларны үтәгәндә тигез шартларны тәэмин итү;

кандидатларны гражданлык хезмәте мәдәниятенә туры килү, профессиональ вәкаләтле булу критерияләре һәм шәхси-эшлекле сыйфатлары нигезендә бәяләү;

конкурста катнашучылар арасыннан, аларның конкурс биремнәрен үтәү һәм конкурс процедураларын үтү нәтиҗәләрен чагыштыру юлы белән, Министрлыкта гражданлык хезмәте вакант вазыйфасына (гражданлык хезмәтенең кадрлар резервы вазыйфасына) туры килә торган затларны билгеләү.

1.5. Министрлыкта гражданлык хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә карата конкурс гражданлык хезмәтенең, законнарга туры китереп, конкурс нигезендә биләргә мөмкин булган вакант вазыйфасы булган очракта Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министры (алга таба – министр) карары нигезендә игълан ителә.

1.6. Конкурс үткәрү турында карар, шушы Нигезләмәнең 1 нче кушымтасына туры китереп, тиешле структур бүлекчә җитәкчесе яки дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге тарафыннан әзерләнгән хезмәт язунамәсе нигезендә министр тарафыннан кабул ителә.

1.7. Министрлыкның кадрлар резервына кертелүгә карата конкурс дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге тарафыннан, Министрлыкның гражданлык хезмәте вакант вазыйфаларын биләү буенча белгечләргә мөмкин булган ихтыяҗын һәм Министрлыктагы кадрлар резервын ел саен бәяләү нәтиҗәләре буенча оештырыла.

Министрлыкның кадрлар резервына кертелүгә карата конкурс Министрлыкның конкурс комиссиясе тарафыннан әлеге Нигезләмәдә каралган тәртиптә үткәрелә.

1.8. Вакант вазыйфаны биләүгә карата конкурс түбәндәге очракларда үткәрелми:

«җитәкчеләр» һәм «ярдәмчеләр (киңәшчеләр)» категорияләрендәге гражданлык хезмәте вазыйфасы вәкаләтләрен билгеле бер чорда биләү өчен билгеләгәндә;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә һәм азат ителә торган, «җитәкчеләр» категориясендәге гражданлык хезмәте вазыйфаларына билгеләгәндә;

вакытлы хезмәт контракты төзелгәндә;

«Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге № 79-ФЗ Федераль законның 28 статьясының 2 өлешендә, 31 статьясының 1 өлешендә һәм 60.1 статьясының 9 өлешендә каралган

очракларда, – гражданлык хезмәткәрен гражданлык хезмәтенең башка вазыйфасына билгеләгәндә;

гражданлык хезмәтенең кадрлар резервына кертелгән гражданлык хезмәткәрен (гражданны) гражданлык хезмәте вазыйфасына билгеләгәндә.

1.9. Вазыйфаи вәкаләтләрне үтәү дәүләт серен тәшкил итә торган белешмәләрдән файдалануга бәйле булган, Министрлык боерыгы нигезендә раслана торган вазыйфалар исемлеге буенча аерым гражданлык хезмәте вазыйфаларына билгеләгәндә конкурс үткәрелмәскә мөмкин.

2. Конкурс комиссиясен формалаштыру һәм аның эшләү тәртибе

2.1. Конкурсны үткәрү өчен Министрлык боерыгы нигезендә даими нигездә гамәл кылучы конкурс комиссиясе төзелә. Конкурс комиссиясенең составы Министрлык боерыгы белән раслана.

2.2. Конкурс комиссиясе рәистән, рәис урынбасарыннан, сәркатиптән һәм комиссия әгъзаларыннан тора. Конкурс комиссиясе составына министр урынбасарлары, дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге башлыгы, юридик бүлек башлыгы, Министрлыкның гражданлык хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) карата конкурс үткәрелә торган структур бүлекчәсе җитәкчесе, Татарстан Республикасы Президенты карамагындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты вәкиле, Министрлык карамагындагы Иҗтимагый совет вәкилләре, бәйсез экспертлар – фәнни һәм мәгариф учреждениеләре, башка оешмаларның вәкилләре, гражданлык хезмәтенә бәйле мәсьәләләр буенча белгечләр кертелә. Министрлык карамагындагы Иҗтимагый совет әгъзаларының һәм бәйсез экспертларның гомуми саны конкурс комиссиясендәге барлык әгъзалар санының кимендә дүрттән бер өлешен тәшкил итәргә тиеш.

2.3. Конкурс комиссиясе рәисе аның эшчәнлегенә җитәкчелек итә, утырыш үткәрү көнен билгели, комиссия утырышларына рәислек итә һәм тиешле документларга имза сала.

Конкурс комиссиясе рәисе булмый торган чорда аның вазыйфаларын конкурс комиссиясе рәисе урынбасары башкара.

Конкурс комиссиясе сәркатибе конкурс комиссиясенең эшен тәэмин итә (гаризалар терки, кабул итә, эшләрне формалаштыра, конкурс комиссиясе утырышлары беркетмәләрен алып бара һ. б.).

2.4. Вазыйфаи вәкаләтләрне үтәү дәүләт серен тәшкил итүче белешмәләрдән файдалануга бәйле булган гражданлык хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә карата конкурс үткәрелгәндә, конкурс комиссиясенең составы Россия Федерациясенең дәүләт сере турындагы законнары нигезләмәләрен исәпкә алып формалаштырыла.

2.5. Конкурс комиссиясенең составы конкурс комиссиясе тарафыннан кабул ителә торган карарларга йогынты ясый алырлык мәнфәгатьләр каршылыгы килеп чыгу мөмкинлеге калмаслык итеп төзелә.

2.6. Конкурс комиссиясе утырышы гражданлык хезмәте вакант вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертелү) буенча кимендә ике кандидат булганда үткәрелә һәм, әгәр дә анда аның әгъзалары саныннан кимендә өчтән

ике өлеше катнашса, тулы хокуклы булып санала. Конкурс комиссиясе утырышын бары тик комиссиянең Министрлыкта гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләүче әгъзалары составында гына үткәрү рөхсәт ителми.

2.7. Конкурс комиссиясе:

конкурсны үткәрү шартларын регламентлый торган документларны, методик материалларны һәм аны үткәрү өчен кирәкле булган башка материалларны раслый;

кандидатлар тарафыннан гражданлык хезмәте вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертелү) өчен тапшырылган документларны тикшергәннән соң, конкурс комиссиясе конкурсның икенче этабына кертелгән кандидатлар исемлеген раслый;

кандидатларның билгеләнгән таләпләргә туры килүен бәяли;

конкурска йомгак ясау, кандидатны конкурста җиңүче итеп тану турында карар кабул итә, аны Министрлыкның кадрлар резервына кертү өчен тәкъдим итә.

2.8. Конкурс үткәрү нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе карары ачык тавыш бирү нигезендә, утырышта катнашкан әгъзалары тавышларының гади күпчелеге белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта конкурс комиссиясе рәисенең тавышы хәл иткеч була. Конкурс комиссиясенең теләсә кайсы әгъзасы, кабул ителгән карар белән риза булмаган очракта, махсус фикерен белдерергә мөмкин, ул конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсендә теркәлә һәм әлеге конкурс комиссиясе әгъзасының имзасы белән беркетелә.

2.9. Конкурс комиссиясенең карары кандидат юклыгында кабул ителә һәм аны гражданлык хезмәте вазыйфасына билгеләү (кадрлар резервына кертү) яисә моннан баш тарту өчен нигез булып тора.

2.10. Конкурс комиссиясе шулай ук тәкъдим холкына ия булган, гражданлык хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә карата конкурста җиңмәгән, ләкин һөнәри һәм шәхси сыйфатлары югары бәяләнгән кандидатны Министрлыкның кадрлар резервына кертү турында карар кабул итәргә хокуклы. Аталган кандидатның ризалыгы белән, ул Министрлыкның кадрлар резервына кертелергә мөмкин.

2.11. Конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан кабул ителә торган карарлар (комиссиянең тавыш бирү нәтиҗәләре), шушы Нигезләмәнең 2 нче кушымтасына туры китереп, конкурс комиссиясе беркетмәсе белән рәсмиләштерелә, анда рәис, рәис урынбасары, сәркатип һәм конкурс комиссиясе утырышында катнашкан конкурс комиссиясе әгъзалары имза сала. Шул ук вакытта конкурс комиссиясе тарафыннан гражданлык хезмәте вазыйфасына беренче мәртәбә билгеләнә торган гражданин өчен сынау чорының озынлыгы буенча киңәшләр бирелергә мөмкин.

2.12. Дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге конкурсның оештырылуын һәм үткәрелүен, конкурс комиссиясесенең эшен тәэмин итә.

## 3. Конкурста катнашучылар

3.1. Министрлыкта дәүләт гражданлык хезмәте вакант вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертелү) буенча конкурста катнашуга шушы Нигезләмәнең

3 нче кушымтасында каралган таләпләргә җавап бирә торган һәм, шушы Нигезләмәнең 4 нче кушымтасына туры китереп, кирәкле документларны һәм материалларны билгеләнгән чорда тапшырган гражданнар (алга таба – кандидатлар) кертелә. Министрлыкның Министрлыкта конкурста катнашу теләген белдергән гражданлык хезмәткәрләренә министр исеменә гариза тапшыру да җитә. Министрлыкта конкурста катнашу теләген белдергән, башка дәүләт органында вазыйфалар биләүче гражданлык хезмәткәрләре Министрлыкка министр исеменә гариза һәм үз кулы белән тутырылган, имзаланган һәм гражданлык хезмәткәренең гражданлык хезмәте вазыйфасын били торган дәүләт органының кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган, Россия Федерациясе Хөкүмәте раслый торган рәвештәге анкетаны, фотоларын теркәп тапшыралар.

3.2. Министрлыкка кандидатлар тарафыннан конкурста катнашу өчен документлар «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәрендәге Министрлыкның рәсми сайтында (алга таба – Министрлык сайты) аларны кабул итү турында игълан урнаштырылган көннән башлап 21 көн эчендә тапшырыла.

3.3. Нигезсез сәбәпләр булмыйча документларны үз вакытында тапшырмау, аларны тулы булмаган күләмдә тапшыру яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшыру гражданнан аларны кабул итүдән баш тартуга нигез булып тора.

Нигезле сәбәпләр аркасында документларны үз вакытында тапшырмаганда, аларны тулы булмаган күләмдә тапшырганда яки рәсмиләштерү кагыйдәләрен бозып тапшырганда, аларны тапшыру чорлары министр боерыгы нигезендә башка вакытка күчерелергә мөмкин.

## 4. Конкурсны үткәрү методикасы

4.1. Конкурсны үткәргәндә кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү методларына таянган, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килми торган конкурс биремнәре һәм процедуралары кулланыла.

4.2. Кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү критерияләре Министрлыкта гражданлык хезмәте вазыйфаларына карата белдерелә торган квалификация таләпләре нигезендә эшләнде.

Конкурста катнашучыларны бәяләү критерияләренең үрнәк исемлеге һәм аларга кыскача сыйфатлама шушы Нигезләмәгә карата 5 нче кушымтада китерелде.

Кандидатларны чагыштыру һәм сайлап алу аларның конкурс биремнәрен үтәү һәм конкурс процедураларын үтү нәтиҗәләре нигезендә гамәлгә ашырыла.

Нәтиҗәләр кандидатлар исемлегендәге балларның күләме рәвешендә күрсәтелә.

4.3. Конкурс ике этапта үткәрелә.

4.4. Конкурсның беренче этабы Министрлык сайтында конкурста катнашу өчен документларны кабул итү турында мәгълүмат урнаштырылган көннән башлана һәм 21 көннән иртәрәк булмаган чорда тәмамлана.

Беренче этапта Министрлыкның дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге түбәндәгеләрне оештыра:

конкурс үткәрелү турында мәгълүмат әзерли һәм Министрлык сайтында һәм «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәренең дәүләт хезмәте өлкәсендәге дәүләт мәгълүматы системасында урнаштыра, әлеге мәгълүмат түбәндәгеләрне үз эченә ала:

гражданлык хезмәте вакант вазыйфасының (кадрлар резервындагы гражданлык хезмәте вазыйфасының) аталышын, әлеге вазыйфаны биләүгә дәгъва кылучыга карата белдерелә торган таләпләрне, гражданлык хезмәтен үтү шартларын, документларны кабул итү урынын һәм вакытын, аталган документларны кабул итү буенча гамәлдә булган чорны, конкурсны үткәрү буенча күздә тотылган датаны, аны үткәрү урынын һәм тәртибен, башка мәгълүмати материалларны.

граждан (гражданлык хезмәткәре) тапшырган документларны тикшерә;

гражданның (гражданлык хезмәткәренең) квалификация таләпләренә туры килүен (һөнәри белем дәрәҗәсен, гражданлык хезмәте (бүтән төрле гражданлык хезмәте) стажын яки белгечлеге буенча эшләү стажын (тәҗрибәсен), әзерлеккә юнәлтелүен, вазыйфаи бурычларны үтәү өчен кирәкле булган һөнәри белемнәрен һәм күнекмәләрен) тикшерә.

4.5. Тикшерү барышында федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының бүтән норматив-хокукый актлары нигезендә гражданның гражданлык хезмәтенә керүенә каршы килә торган шартлар ачыкланган очракта, аңа язмача рәвештә конкурсга катнаштырудан баш тартуның сәбәпләре хакында министр тарафыннан хәбәр ителә.

4.6. Министрлыкта гражданлык хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) дәгъва кылган, ләкин конкурста катнашуга кертелмәгән зат әлеге карарны Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять кылырга хокуклы.

4.7. Министрлыкта гражданлык хезмәтенең бер вакант вазыйфасына (гражданлык хезмәтенең кадрлар резервы вазыйфасына) билгеләнгән квалификация таләпләренә җавап бирә торган кимендә ике кандидат булу конкурсның беренче этабын төгәлләү шарты булып тора, бу хәл кандидатларны алга таба сайлау мөмкинлеген тәэмин итә.

Кандидатлар булмаганда яки вазыйфага карата квалификация таләпләренә җавап бирә торган бары тик бер генә кандидат булган очракта, конкурс узмаган дип таныла. Бу очракта бердәнбер кандидатка конкурс комиссиясе карары буенча конкурс комиссиясенең таләп ителгән кандидатлар саны булмауга бәйле рәвештә узмаган дип танылуы хакында язмача хәбәр ителә.

4.8. Конкурс комиссиясе рәисе тарафыннан расланган, билгеләнгән таләпләргә җавап бирүче һәм алга таба конкурста катнашу тәкъдиме бирелгән кандидатларның исемлеге конкурсның беренче этап нәтиҗәсе булып тора.

4.9. Конкурсның беренче этабы узгач, конкурс комиссиясе рәисе тарафыннан конкурсның икенче этабын үткәрү датасы, вакыты һәм урыны

турында карар кабул ителгәч, конкурс комиссиясе конкурсның икенче этабын үткәрә.

Министрлыкның дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге, конкурсның икенче этабы башланганчыга кадәр 15 көннән соңга калмыйча, конкурстка катнашуга кертелгән гражданнарга (гражданлык хезмәткәрләренә) аның үткәрелү датасы, урыны һәм вакыты турында хәбәрләр җибәрә.

4.10. Конкурсның икенче этабында конкурс комиссиясе тарафыннан кандидатларның һөнәри һәм шәхси үзенчәлекләрен бәяләү гамәлгә ашырыла.

4.11. Конкурсны үткәргәндә конкурс комиссиясе кандидатларны алар тарафыннан тапшырылган белем, гражданлык яки бүтән дәүләт гражданлык хезмәтен үтәү, башка хезмәт эшчәнлеген башкару турындагы документлары нигезендә, шулай ук Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына каршы килми торган, кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын бәяләү методларыннан файдаланып, конкурс процедуралары нигезендә, шул исәптән Министрлыкта гражданлык хезмәте вакант вазыйфасы (гражданлык хезмәтенең кадрлар резервы вазыйфасы) буенча вазыйфаи бурычларны үтәүгә бәйле булган мәсьәләләрдә тест һәм шәхси әңгәмә үткәрү юлы белән бәяли.

4.12. Министрлыкта гражданлык хезмәтенең билгеле бер вакант вазыйфасына (гражданлык хезмәтенең кадрлар резервы вазыйфасына) кандидатларга тест үткәрү Татарстан Республикасы Президенты карамагындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаментының 2016 елның 11 гыйнварындагы № 1 карары белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләренә, Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфаларын биләүгә дәгъвалык итүче гражданнарга тест үткәрү методикасы нигезендә гамәлгә ашырыла.

4.13. Тест үткән кандидатлар белән шәхси әңгәмәләр конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан үткәрелә.

Шәхси әңгәмә кандидатларның булачак һөнәри хезмәт итү эшчәнлеге темасы буенча конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан бирелә торган сорауларга җавапларыннан гыйбарәт, әңгәмә барышында конкурс комиссиясе кандидатларның һөнәри һәм шәхси сыйфатларын гражданлык хезмәте вазыйфасына һәм әлеге вазыйфа буенча вазыйфаи регламентның бүтән нигезләмәләренә карата тиешле квалификация таләпләреннән чыгып, шулай ук әлеге Нигезләмәгә һәм Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының дәүләт гражданлык хезмәте турындагы законнарында билгеләнгән башка нигезләмәләргә таянып бәяли.

4.14. Конкурс комиссиясенең конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсенә кертелгән карары конкурсның икенче этап нәтиҗәсе һәм бер үк вакытта конкурсның йомгаклау нәтиҗәсе булып тора.

4.15. Кандидатлар тарафыннан алынган тавышлар саны, кандидатлар тарафыннан биләү өчен дәгъва кылына торган вазыйфа караган структур бүлекчә җитәкчесенең (Министрлык җитәкчелегенең) фикере Министрлыкта гражданлык хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) кандидат турында карар кабул итү һәм конкурска йомгак ясау өчен нигез булып

тора.

«Риза» тавышларын иң күп җыйган кандидат конкурста җиңүче дип танылa.

4.16. Әгәр дә конкурсны үткәрү нәтиҗәсендә гражданлык хезмәте вакант вазыйфасы (гражданлык хезмәтенең кадрлар резервы вазыйфасы) буенча барлык кирәкле таләпләргә җавап бирә торган кандидатлар ачыкланса, конкурс комиссиясе өстәмә конкурс сынауларын үткәрү турында карар кабул итәргә яки яңа конкурс үткәрү тәкъдимен кертергә хокуклы.

4.17. Гражданлык хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә карата конкурс нәтиҗәләре буенча конкурста җиңүчене гражданлык хезмәте вакант вазыйфасына билгеләү турындагы Министрлык боерыгы чыгарыла һәм аның белән хезмәт контракты төзелә. Конкурс комиссиясе шулай ук тәкъдим холкына ия булган, гражданлык хезмәте вакант вазыйфасын биләү буенча конкурста җиңмәгән, ләкин һөнәри һәм шәхси сыйфатлары югары бәягә лаек булган кандидатны Министрлыкның кадрлар резервына кертү турында карар кабул итәргә хокуклы.

Гражданлык хезмәте вакант вазыйфасы караган шул ук төркемдәге гражданлык хезмәте вазыйфасын биләү өчен, кандидатның ризалыгы белән, аны Министрлыкның кадрлар резервына кертү турында Министрлык боерыгы чыгарыла.

Гражданлык хезмәткәрен (гражданны) – конкурста җиңүчене кадрлар резервына кертү, Министрлык боерыгы күчермәсен гражданлык хезмәткәренең шәхси эшенә теркәп, Министрлык боерыгы белән рәсмиләштерелә.

4.18. Гражданлык хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) кандидат конкурс комиссиясе карарын Россия Федерациясе законнары нигезендә шикаять кылырга хокуклы.

4.19. Конкурс нәтиҗәләре турындагы хәбәрләр конкурста катнашучыларга конкурс тәгәлләнгәннән соң 7 көнлек чорда язмача рәвештә җибәрелә. Конкурс нәтиҗәләре турындагы мәгълүмат, шулай ук, аталган чорда Министрлык сайтында һәм «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникацияләр челтәренең дәүләт хезмәте өлкәсендәге дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырыла.

4.20. Министрлыкта гражданлык хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) дәгъва кылган, ләкин конкурста катнашуга кертелмәгән кандидатларның һәм конкурста катнашкан кандидатларның документлары язмача гаризалары буенча конкурс тәмамланган көннән соң өч ел дәвамында аларга кайтарып бирелергә мөмкин. Әлеге чор тәмамланганчыга кадәр документлар Министрлык архивында саклана, аннан соң юкка чыгарылырга тиеш.

4.21. Конкурста катнашуга бәйле чыгымнар (конкурс үткәрелгән урынга бару һәм кайту, торак бинага түләү, яшәү, элемтә чаралары хезмәтләреннән файдалану һәм башкасы) кандидатлар тарафыннан үз акчалары хисабыннан түләнә.

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) карата конкурс үткәрү турында нигезләмәгә
1 нче кушымта

Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министры
И.Ә.Фәйзуллинга

______________________________________
(фамилия һәм инициаллар)

ХЕЗМӘТ ЯЗУНАМӘСЕ

20__ елның «___»____________

Сездән

______________________________________________________________________
(вазыйфа (вазыйфалар төркеме)аталышы)

______________________________________________________________________
(структур бүлекчә аталышы)

______________________________________________________________________
дәүләт гражданлык хезмәте вакант вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертелү) буенча конкурс игълан итүегезне сорыйм.

Аталган вазыйфаны биләү өчен дәгъва кылучыга карата түбәндәге таләпләр белдерелә: ________________________________________________.

____________________ ____________________ ____________________
(вазыйфа аталышы) (имза) (имзаның аңлатмасы)

КИЛЕШТЕРЕЛДЕ:
Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министры урынбасары

______________________________ ______________________________
(имза, дата) (имзаның аңлатмасы)

Татарстан Республикасы Төзелеш,
архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы
министрлыгында Татарстан Республикасы
дәүләт гражданлык хезмәте вакант вазыйфасын
биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) карата
конкурс үткәрү турында нигезләмәгә
2 нче кушымта

башлана: _____________ сәг.
тәмамлана: __________ сәг.

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының конкурс комиссиясе утырышының
20___елның «__»__________ №____
беркетмәсе

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгының конкурс комиссиясе утырышында биләнәчәк вакант вазыйфага (Министрлыкның кадрлар резервына кертелүгә) карата конкурста сайлап алу буенча тавыш бирелде

______________________________________________________________ .
(вазыйфа аталышы, структур бүлекчә (вазыйфалары төркеме) аталышы)

Утырышта _____ конкурс комиссиясенең____әгъзасы катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре:

| №№ п/п | Кандидатның фамилиясе һәм инициаллары | Тавышлар саны | |
|---|---|---|---|
| | | «риза» | «каршы» |
| 1. | | | |
| 2. | | | |

Тавыш бирү нәтиҗәсендә__________________________________________
(кандидатның фамилиясе һәм инициаллары)

тавыш бирүдә катнашкан конкурс комиссиясе әгъзаларыннан иң күп тавыш туплады.

Шул ук вакытта конкурс комиссиясе тарафыннан озынлыгы _________________________ булган сынау вакытын билгеләү тәкъдим ителде.

Конкурс комиссиясе рәисе _______________ _______________________
(имза) (имзаның аңлатмасы)

Конкурс комиссиясе
рәисе урынбасары______________ _________________________
(имза) (имзаның аңлатмасы)

Конкурс комиссиясе сәркатибе______________ _________________________
(имза) (имзаның аңлатмасы)

Конкурс комиссиясе әгъзалары:______________ _______________________
(имза) (имзаның аңлатмасы)

Документ создан в электронной форме. № 01-09-3773 от 03.03.2017. Исполнитель: Петрова С.А.
Страница 31 из 38. Страница создана: 02.03.2017 17:43
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Татарстан Республикасы Төзелеш,
архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы
министрлыгында Татарстан Республикасы
дәүләт гражданлык хезмәте вакант вазыйфасын
биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) карата
конкурс үткәрү турында нигезләмәгә
3 нче кушымта

## Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вакант вазыйфаларын биләү (кадрлар резервына кертелү) өчен кандидатларга карата таләпләр

1. Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында дәүләт гражданлык хезмәте (алга таба – гражданлык хезмәте) вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) карата конкурста катнашу хокукына Россия Федерациясенең 18 яшьлек чорына җиткән, Россия Федерациясенең дәүләт телен белгән, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән, Министрлыкта Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вакант вазыйфасын (Татарстан Республикасы гражданлык хезмәтенең кадрлар резервы вазыйфасын) биләү өчен зарури таләпләргә җавап бирә торган гражданнары ия була.

Гражданлык хезмәткәре гомуми нигезләрдә, үткәрелү чорына нинди вазыйфа биләвенә бәйсез рәвештә, Министрлыкта гражданлык хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) карата конкурста катнашырга хокуклы.

2. Гражданлык хезмәтенә керү һәм аны үтү өчен Россия Федерациясенең дәүләт гражданлык хезмәте турындагы законнарында билгеләнгән чикләмәләренә бәйле рәвештә гражданин гражданлык хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) карата конкурста катнашуга кертелми.

3. Гражданлык хезмәте вазыйфасын биләү (кадрлар резервына кертелү) өчен һөнәри белем дәрәҗәсенә карата законнарда билгеләнгән квалификация, гражданлык хезмәте яки белгечлек буенча эш стажы таләпләренә, шулай ук Министрлыкның дәүләт гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан вазыйфаларын үтәү өчен зарури булган һөнәри белемнәргә һәм күнекмәләргә карата квалификация таләпләренә җавап бирү таләп ителә.


ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Татарстан Республикасы Төзелеш,
архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы
министрлыгында Татарстан Республикасы
дәүләт гражданлык хезмәте вакант вазыйфасын
биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) карата
конкурс үткәрү турында нигезләмәгә
4 нче кушымта

## Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вакант вазыйфаларын биләү (кадрлар резервына кертелү) буенча кандидатлар тарафыннан тапшырыла торган документлар һәм материаллар исемлеге

1. Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министры исеменә шәхси гариза (Исемлеккә карата кушымта).

2. Кандидатның шәхесен таныклый торган документ күчермәсе (паспорт, хәрби билет, шәхес таныклыгы).

3. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2005 елның 26 маендагы № 667-р карары белән расланган рәвештә, үз кулы белән тутырылган һәм имзаланган анкета, 3х4 фотосын теркәп.

4. Һөнәри белем алу турында, шулай ук гражданның теләгенә карап – өстәмә белем алу, фәнни дәрәҗә, фәнни исем бирелү турындагы документларның нотариаль яктан яки эшләү (хезмәт итү) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган күчермәләре.

5. Хезмәт кенәгәсенең (эшкә (хезмәт итүгә) бәйле эшчәнлек беренче мәртәбә гамәлгә ашырыла торган очраклардан кала) нотариаль яктан яки эш (хезмәт итү) урыны буенча кадрлар хезмәте тарафыннан таныкланган күчермәсе яки гражданның эшкә бәйле (хезмәт итү) эшчәнлеген раслый торган бүтән документлар.

6. Мәҗбүри пенсия иминиятләштерүенең иминият таныклыгы күчермәсе.

7. Физик затны салым органында исәпкә алу турында таныклык күчермәсе.

8. Медицина оешмасының дәүләт хезмәтенә керү өчен комачаулый торган авыру булуы (булмавы) турында бәяләмәсе (№ 001-ГС/у рәвешендә).

9. Алынган керемнәр һәм милекчелек хокукында ия булган, салым салынучы объектларны тәшкил итүче мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмә.

10. «Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге № 79-ФЗ Федераль законда, бүтән федераль законнарда, Россия Федерациясе Президенты указларында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларында каралган башка документлар.

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) карата конкурс үткәрү турында нигезләмәнең Гражданлык хезмәтенең вакант вазыйфаларын биләү буенча кандидатлар тарафыннан тапшырыла торган документлар һәм материаллар исемлегенә кушымта

Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министры
И.Ә.Фәйзуллинга

________________________________________
(фамилия, инициаллар)

________________________________________
түбәндәге адреста яшәүче: ____________
________________________________________
тел. ____________________________________
(эш, өй, кесә, e-mail)

гариза

Мине Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең түбәндәге вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) карата конкурста катнашуга кертүегезне сорыйм:____________________________________
(вазыйфа, вазыйфалар төркеме аталышы)

______________________________________________________________________.
(структур бүлекчә аталышы)

«Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге № 79-ФЗ Федераль закон, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә карата конкурс турында» 2005 елның 1 февралендәге № 112 Указы, «Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте турында» 2003 елның 16 гыйнварындагы № 3-ТРЗ Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгында дәүләт гражданлык хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә карата конкурс үткәрү турында нигезләмә белән, шулай ук вакант вазыйфага карата белдерелә торган квалификация таләпләре белән танышмын.

Дәүләт серен һәм закон белән саклана торган башка серне тәшкил итә торган белешмәләрдән файдалануга карата рөхсәт алуны рәсмиләштерү процедурасы үткәрелү белән килешәм.

Конкурсны үткәрү датасы һәм урыны турында e-mail яки күрсәтелгән кесә телефоны номерына СМС-хәбәр җибәрү ярдәмендә хәбәр алуга ризамын.

«Персональ белешмәләр турында» 2006 елның 27 июлендәге № 152-ФЗ Федераль законның 3 һәм 9 статьялары нигезендә Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгына һәм Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте белән идарә итү органына югарыда аталган Татарстан Республикасы дәүләт органына эшкә кергәндә минем тарафтан тапшырылган минем персональ белешмәләремне (мәгълүматларымны) эшкәртүгә (җыюны, яздыруны, системага салуны, туплауны, саклауны, тәгаенләүне (яңартуны, үзгәртүне), чыгаруны, файдалануны, тапшыруны (таратуны, биреп торуны, файдалану мөмкинлеген тудыруны), шәхессезләндерүне, ябуны, юкка чыгаруны, бетерүне кертеп, автоматлаштыру чараларыннан файдаланып яки мондый чаралардан файдаланмыйча башкарыла торган теләсә нинди гамәл (операция) яки гамәлләр җыелмасын кылуга) ризалык бирәм, шул исәптән: фамилиям, исемем, атам исеме; элеккеге фамилиям, исемем, атам исеме; туу датам һәм урыным; җенесем; гражданлыгым; чит телләрне һәм Россия Федерациясе халыклары телләрен белүем; белемем; фәнни дәрәҗәм; фәнни исемем;

өстәмә һөнәри белемем; һөнәрем (белгечлегем); эш стажым; дәүләт бүләкләрем һәм башка бүләкләрем, үзгәлек билгеләрем булу (кем тарафыннан һәм кайчан бүләкләнгән); эшкә алынуым, икенче эшкә күчүләрем, билгеләнүләрем һәм эштән куылуым турында белешмәләр; командировкалар, отпусклар, вакытлыча эшкә сәләтсез булуым турында белешмәләр; гаилә хәлем (шул исәптән: гаилә составы, туганлык дәрәҗәсе, якын туганнарымның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туу датасы, аларның эшләү һәм белем алу урыннары); паспорт белешмәләрем; гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу турында таныклыгым; яшәү һәм тору урыным буенча адресым; элемтә өчен телефон номерым; дәүләт пенсия иминиятләштерүенең иминият таныклыгы номеры; хәрби исәпкә алыну турындагы белешмәләрем; салым түләүченең тәңгәллек номеры; суд хөкеменә тартылган булуым (булмавым); эшләү чорында рәсмиләштерелгән, дәүләт сереннән файдалануга рөхсәт; фотосурәтем; медицина оешмасы бәяләмәсе, шулай ук «Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенең һәм муниципаль хезмәтнең кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүматы системасы кысаларында минем хезмәт эшчәнлегемне үтү мәсьәләләренә карый торган һәм кадрлык эшен башкару өчен кирәкле булган башка төрле персональ белешмәләр.

Югарыда аталган персональ белешмәләрне шулай ук хезмәт законнарын тормышка ашыруны, Россия Федерациясенең һәм Татарстан Республикасының башка норматив-хокукый актлары үтәлешен тәэмин итү максатларында тапшырам.

Мин Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте белән идарә итү органының минем персональ белешмәләремне миңа медицина хезмәтләре күрсәтелүне, пенсия белән тәэмин ителүемне, спорт чараларында катнашуымны оештыру максатларында, билгеләнгән башка шартларда Татарстан Республикасының вәкаләтле дәүләт органнарына тапшырырга хокуклы булуы белән килешәм. Югарыда аталган Татарстан Республикасы дәүләт органнарының аталышы һәм адресы алар турында Татарстан Республикасының норматив-хокукый актларында расланган нигезләмәләрдә билгеләнгән.

Мин түбәндәгеләр хакында таныштым:

1) персональ белешмәләрне эшкәртүгә бирелгән ризалык шушы килешүгә имза салган датадан башлап Татарстан Республикасы дәүләт органында эшләгән барлык чор дәвамында гамәлдә була;

2) персональ белешмәләрне эшкәртүгә бирелгән ризалык минем тарафтан ирекле рәвештә язылган гариза нигезендә кайтарып алынырга мөмкин;

3) персональ белешмәләрне эшкәртүгә бирелгән ризалыкны кайтартып алган очракта, «Персональ белешмәләр турында» 2006 елның 27 июлендәге № 152-ФЗ Федераль законның 6 статьясының 1 өлешендәге 2-11 пунктларында, 10 статьясының 2 өлешендә һәм 11 статьясының 2 өлешендә күрсәтелгән нигезләр булганда, югарыда аталган органнар персональ белешмәләрне эшкәртүне дәвам иттерергә хокуклы;

4) хезмәт мөнәсәбәтләре туктатылганнан соң персональ белешмәләр Россия Федерациясенең гамәлдәге законнарында каралганча документларны саклау чоры дәвамында саклана

Югарыда аталган органнар тарафыннан минем персональ белешмәләремне эшкәртү «Персональ белешмәләр турында» 2006 елның 27 июлендәге № 152-ФЗ Федераль закон таләпләре белән тулысынча туры китереп гамәлгә ашырыла.

Гаризага түбәндәгеләрне терким: (теркәлә торган документларны санап чыгарга).

____________ ____________________ ____________________

(дата) (имза) (имзаның аңлатмасы)

Татарстан Республикасы Төзелеш,
архитектура һәм торак-коммуналь
хуҗалыгы министрлыгында
Татарстан Республикасы дәүләт
гражданлык хезмәте вакант
вазыйфасын биләүгә (кадрлар
резервына кертелүгә) карата конкурс
үткәрү турында нигезләмәгә
5 нче кушымта

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте вакант вазыйфасын биләүгә (кадрлар резервына кертелүгә) карата конкурста катнашучыларны бәяләү критерияләре

## 1. Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте мәдәниятенә туры килү

1.1. Һөнәри мотивация

Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтендә һөнәри яктан үз-үзеңне тормышка ашыруга омтылу, дәүләт идарәлеге өлкәсендә хезмәттә үсүгә юнәлеш алу.

1.2. Гражданлык позициясе

Эшчәнлектә җәмгыятькә һәм дәүләткә хезмәт итү, законнарны, хезмәт этикасы кагыйдәләрен үтәү принципларына таяну.

1.3. Һөнәри позицияләр активлыгы

Куелган мәсьәләләрне хәл иткәндә инициатива күрсәтергә омтылу; мөмкин булган иң яхшы нәтиҗәне алу өчен әһәмиятле дәрәҗәдә көч куюга әзерлек, физик һәм хискә бәйле басым шартларында нәтиҗәле гамәл кылуга сәләтле булу (стрессларга каршы торучанлык).

1.4. Үз-үзеңне үстерүгә әзер булу

Белемнәреңне, осталыкларыңны һәм күнекмәләреңне камилләштерүгә, фикерләү даирәсен киңәйтүгә, катнаш һөнәр өлкәләрендә белемнәр һәм тәҗрибә алуга даими рәвештә омтылу.

## 2. Гражданлык хезмәткәренең һөнәри вәкаләтлелеге

2.1. Белем дәрәҗәсе

Төп һәм өстәмә һөнәри белем дәрәҗәсе, юнәлеше һәм сыйфаты.

2.2. Һөнәри тәҗрибә

Тиешле һөнәр өлкәсендә эшләү дәвере һәм үзенчәлекләре;

һөнәри эшчәнлектә билгеле бер нәтиҗәләргә ирешүе;

Документ создан в электронной форме. № 01-09-3773 от 03.03.2017. Исполнитель: Петрова С.А.
Страница 36 из 38. Страница создана: 02.03.2017 17:43
ЭЛЕКТРОННЫЙ ТАТАРСТАН

Карьерасындагы үзенчәлекләре.

2.3. Махсус һөнәри белемнәр, осталыклар һәм күнекмәләр

Вазыйфаи бурычларны үтәү мөмкинлеген бирә торган, тиешле өлкәдәге һөнәри белемнәр дәрәҗәсе;

һөнәри эшчәнлеген регламентлый торган Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарын белүе;

заманча профессиональ технологияләр белән эш итә белүе.

2.4. Гомуми инструменталь күнекмәләр

Һөнәри эшчәнлекнең гомуми нәтиҗәлелеген арттыра торган күнекмәләргә ия булу дәрәҗәсе (компьютерда эш итә белүе, гомуми грамоталы булуы, чит телләрне белүе һ.б.).

## 3. Гражданлык хезмәткәренең шәхси-эшлекле сыйфатлары

3.1. Аналитик сәләтләре

Катлаулы, мәгълүматларны анализлауны һәм структуралаштыруны таләп итүче мәсьәләләрне хәл итәргә ярдәм итүче системалылык һәм зирәк фикерләү дәрәҗәсе;

яңа, стандарт булмаган чишелешләр табу сәләте.

3.2. Нәтиҗәле коммуникацияләү күнекмәләре

Эшлекле сөйләм этикасын үтәве;

махсус фикереңне дәлилле яклый белүгә һәм оппонентларны ышандыра алуга сәләтле булуы;

эшлекле сөйләшүләрне алып бару күнекмәләренә ия булуы.

3.3. Җаваплылык

Каралар кабул иткәндә нигезләнгәнлек һәм мөстәкыйльлек;

нәтиҗәгә ирешүдә үз өстеңә алган йөкләмәләрне үтәргә әзер булуы.

3.4. Оештыру сәләте

Үз эшчәнлегеңне һәм буйсынып эшләүчеләрнең эшчәнлеген нәтиҗәле планлаштыруы, вазыйфаларны, вәкаләтләрне һәм җаваплылыкны бүлү хисабына нәтиҗәләргә ирешә белүе.

Документ создан в электронной форме. № 01-09-3773 от 03.03.2017. Исполнитель: Петрова С.А.
Страница 37 из 38. Страница создана: 02.03.2017 17:43